| | |
|---|---|
| **ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ САРМАШ-БАШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ САРМАШ-БАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**15.01.2019** с.Сармаш-Баш № 1

**Сармаш-Баш авыл җирлеге гражданнарының үзара салым акчаларын җыю тәртибе турында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федраль закон, «Җирле референдум турында» 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Сармаш-Баш авыл җирлеге уставы белән, Татарстан Республикасы Зәй районы Территориаль сайлау комиссияс кабул ителгән «20» февраль 2014 елдагы № 76 «Зәй муниципаль районы Сармаш-Баш авыл җирлеге территориясендә 2018 елның 18 ноябрендә узган “Җирле референдумның нәтиҗәләре турында» исемле карарны гамәлгә ашыру максатыннан,
Сармаш-Баш авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1.Сармаш-Баш авыл җирлеге гражданнарының үзара салым акчаларын җыюның әлеге тәртибен расларга.

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокуки мәгълумати рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Зәй муниципаль районы рәсми сайтының «Авыл җирлекләре» бүлекчәсендә урнаштырырга һәм халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплыгымда калдырам.

Башкарма комитет
җитәкчесе Р.М.Фасхутдинов

Сармаш-Баш
башкарма комитетының
2019 елның 1 № лы
карарына 1 нче кушымта

**Сармаш-Башавыл җирлеге**
**гражданнарының үзара салым акчаларын җыю тәртибе**

1. Әлеге Тәртип Сармаш-Баш авыл җирлеге гражданнарының үзара салым акчаларын җыю кагыйдәләрен билгели.

2. Гражданнарның үзара салым акчаларын түләү 18 яшькә җиткән һәм Сармаш-Баш авыл җирлеге территориясендә теркәлгән гражданнар тарафыннан 2019 елның 15 февраленә кадәр, гражданнарның 1 нче группа инвалид категорияләреннән тыш, аларның җирле референдумда (гражданнар җыенында) катнашу-катнашмавына һәм аларның тавыш бирү барышында белдергән мөнәсәбәтләреннән бәйсез рәвештә түләнә.

3. Түбәндәге игътибарга лаеклы сәбәпләр булганда:

а) Вакытлыча хезмәткә яраксыз булу( 6 айдан күбрәк)

б) Оешманың эшчәнлеге туктатылу сәбәпле һәм оешманың штатында хезмәткәрләр саны кыскарту сәбәпле эштән азат ителү.

гражданнарга гариза нигезендә ике айдан артык булмаган вакытка, түләү кертүне кичектереп тору рөхсәт ителергә мөмкин.

4. Бер тапкыр түләнә торган түләүне башкару турындагы белдерү кәгазе бланкы гражданнар игътибарына белдерү такталарына, «Татарстан Республикасы хокуки мәгълумати рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Зәй муниципаль районы рәсми сайтының «Авыл җирлекләре» бүлекчәсендә кую, шулай ук имза куйдырып шәхсән тапшыру яки почта элемтәсе аша юллау юлы белән җиткерелә.

Белдерү кәгазе үз эченә гражданнарның үзара салым акчаларын түләү реквизитларын, бер тапкыр түләнә торган акчаның тулысынча яки киметелгән күләмдәге суммасын, түләү вакытын алырга тиеш.

5. Гражданнардан алынган үзара салым акчалары Сармаш-Баш авыл җирлеге лицевой счетына күчереләләр.

6. Түләүләрне башкару гражданнар тарафыннан акчаларны физик затлар теләге буенча исәп-хисапларны гамәлгә ашыру, акчаларны почта аша күчерү (исәп-хисап оешмалары), Сармаш-Баш авыл җирлеге башкарма комитеты аша күчерү хокукына ия булган оешма аша күчерү яки https://uslugi.tatarstan.ru/ сылтамасы буенча Татарстан Республикасы дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша күчерү хокукына ия булган оешмалар аша гамәлгә ашырыла.

7. Түләү квитанциясе, чек-ордер, түләү фактын раслаган башка документлар түләү фактын раслау булып торалар.

8. Гражданнарның билгеләнгән срокта күчерелмәгән үзара салым акчалары закон тарафыннан билгеләнгән тәртиптә түләттерелә.

Сармаш-Баш
башкарма комитетының
2019 елның 1 № лы
карарына 2 нче кушымта

Сармаш-Баш башкарма комитеты
(*муниципаль берәмлек исеме)*
бюджетына үзара салым буенча бер тапкыр түләнә торган түләү кертү турында
БЕЛДЕРҮ КӘГАЗЕ № _______________

Түләүченең Ф.И.Ә.и.
______________________________________________________________________________
Адрес: ________________________________________________________________
Нигезләмә ____________________________________________________________
Сезгә ________________________ көнгә кадәрге вакыт эчендә
_____________________________________________________ чараны гамәлгә ашыру
буенча ______________ сум күләмендә бер тапкыр түләнә торган түләүне түбәндәге реквизитларга күчерергә кирәк:
Кабул итүче як банкы БИК _______________________________________
Сч. № ___________________________________
Кабул итеп алучы Сч. № __________________________________________
ИНН _______________________________________
КПП _______________________________________
КБК ________________ ОКАТО ___________________
Түләүнең билгеләнеше

Җитәкче __________________ __________________________________________
М.У. (имза) (тулысынча язылыш)

**- - - - - - - - - - - - - - - - - - кисеп алу сызыгы - - - - - - - - - - - - - - -**

________________
(*муниципаль берәмлек исеме)*
бюджетына үзара салым буенча бер тапкыр түләнә торган түләүне
_________________ сум күләмендә түләү турында № ________ белдерү кәгазе.
Түләүченең Ф.И.Ә.и. __________________________________________________________
Адрес:
______________________________________________________________________________
Кабул ителде «__» ________________ 20__ ел.
________________________________________
(түләүченең имзасы)
*Искәрмә. Белдерү кәгазе түләүчегә шәхсән тапшырылган очракта, түләү кәгазе өлеше (отрывной корешок) тутырыла һәм ________________ җирлеге башкарма комитетында кала.*